ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 152-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.У. Әхмәтов, В.В. Вавилов, О.М. Воронова, А.И. Зыятдинов, А.Н. Надыршина, А.С. Созинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 152-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 566-VII ДС

152-1

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.У. Әхмәтов,
В.В. Вавилов,
О.М. Воронова,
А.И. Зыятдинов,
А.Н. Надыршина,
А.С. Созинов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

**Татарстан Республикасы**
**ЗАКОНЫ**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 75 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

$10^1$) Федераль законның 69 статьясындагы $3^3$ өлешендә күрсәтелгән затларны эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыру, шул исәптән үз вәкаләтләре чикләрендә әлеге затларга өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләү;»;

2) 5 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $4^3$ пункт өстәргә:

$4^3$) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары буйсынуындагы илкүләм медицина тикшеренүләр үзәкләре эшчәнлеген оештыру;»;

б) $16^5$ пунктта «тәртибен» сүзеннән соң «Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында каралган методик күрсәтмәләр нигезендә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статья белән үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасы 2026 елның 30 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасы 2026 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законын 2025 елның 17 ноябрендәге 424-ФЗ номерлы, 2025 елның 28 декабрендәге 515-ФЗ номерлы, 2025 елның 29 декабрендәге 550-ФЗ номерлы федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

Закон проектының 1 статьясындагы 1 пунктында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә сәламәтлек саклау өлкәсендә остазлык башкарылырга тиешле затларны эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыруны, шулай ук күрсәтелгән затларга өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләүне кертү тәкъдим ителә.

Закон проектының 1 статьясындагы 2 пунктында Татарстан Республикасы Законының гамәлдәге редакциясенең Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкаләтләре турындагы 5 статьясына илкүләм медицина тикшеренү үзәкләре эшчәнлеген оештыру турында яңа вәкаләт өстәү тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы $16^5$ пунктына төгәлләштерү характерындагы үзгәрешләр кертелә, алар нигезендә Татарстан Республикасы җыелма командалары спортчыларын медик-биологик яктан тәэмин итүне оештыру тәртибе 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында каралган методик күрсәтмәләр нигезендә расланырга тиеш.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар таләп итми.